КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 6 март г.Казань № 168

2025 елга кадәр Татарстан Республикасында спорт резервын әзерләү концепциясен раслау турында

Татарстан Республикасында спорт резервын әзерләү эшенең нәтиҗәлелеген күтәрү, шулай ук спорт әзерлеген узучы затларның спорт осталыгы дәрәҗәсен арттыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2025 елга кадәр Татарстан Республикасында спорт резервын әзерләү концепциясен;

2025 елга кадәр Татарстан Республикасында спорт резервын әзерләү концепциясен тормышка ашыру буенча чаралар планын.

2. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына бу карар белән расланган Концепцияне һәм планны агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә тормышка ашыруны тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына бу карар белән расланган Концепция нигезләренә таянып эш итүне тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 6 март, 168 нче
карары белән расланды

2025 елга кадәр Татарстан Республикасында спорт резервын әзерләү концепциясен тормышка ашыру буенча чаралар планы

| Т/с | Чара исеме | Тормышка ашыру вакыты | Җаваплы үтәүчеләр | Йомгаклау документы |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| I. Спорт резервын әзерләүне норматив хокукый җайга салу | | | | |
| 1. | Россия Федерациясе законнарына туры китерү өлешендә спорт резервын әзерләү буенча Татарстан Республикасы законнарына, муниципаль хокукый актларга һәм спорт мәктәпләренең локаль актларына үзгәрешләр кертү мониторингы | ел саен, хисап елыннан соң килә торган елның II кварталы | Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, Татарстан Республикасының җирле үзидарә органнары (килешү буенча килешү буенча) | Россия Федерациясе Спорт министрлыгына доклад |
| 2. | Россия Федерациясе Хөкүмәте боерыгы нигезендә җирле үзидарә органнары һәм спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы оешмалар эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары, күрсәткечләре (максатчан индикаторлары) һәм инструментлары (методикалары) системасын камилләштерү | 2021 ел | Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, Татарстан Республикасының җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы боерыгы |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| II. Спорт резервын әзерләү системасы белән идарә итүне, аның эшчәнлеген координацияләү һәм аны методик яктан тәэмин итүне камилләштерү | | | | |
| 3. | Спортчыларны әзерләүгә өлеш керткән тренерларны кызыксындыруны һәм бүләкләүне исәпкә алып, спорт әзерлегенең алдагы этапларында спорт әзерлеген алга таба үтү өчен спортчыларны бер спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмадан башка оешмага күчерү буенча Россия Федерациясе Спорт министрлыгы боерыгы белән расланган тәртипне гамәлгә кертү | 2021 – 2022 еллар | Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, төбәк спорт федерацияләре (килешү буенча), Татарстан Республикасының җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы боерыгы |
| 4. | Спорт әзерлеге стандартларын һәм программаларын гамәлгә ашырганда фәнни, медицина һәм медик-биологик яктан тәэмин итү буенча Россия Федерациясе Спорт министрлыгы тарафыннан расланган чаралар комплексын спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмалар эшендә гамәлгә кертү | 2020 – 2021 еллар | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, төбәк спорт федера-цияләре (килешү буенча), Татарстан Республикасының җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | Россия Федерациясе Спорт министрлыгына доклад |
| 5. | Россия Федерациясе Спорт министрлыгы тарафыннан расланган бертип программалар нигезендә эшләнгән спорт әзерлеге программаларын гамәлгә кертү һәм гамәлгә ашыру | 2021 – 2025 еллар | Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, төбәк спорт федерацияләре (килешү буенча), Татарстан Республикасының җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | спорт төрләре буенча спорт әзерлеге программалары |
| 6. | Оешмалар тарафыннан физик культура | 2020 – 2021 | Татарстан Республикасы Спорт | Россия Федерациясе |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | һәм спорт өлкәсендә спорт әзерлеге программаларын һәм өстәмә гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыруны тәэмин итү өчен спорт объектларыннан бергә файдалану механизмнары буенча Россия Федерациясе Спорт министрлыгы тарафыннан кабул ителгән методик тәкъдимнамәләрне гамәлгә кертү | еллар | министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республика-сының җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | Спорт министрлыгына доклад |
| III. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның тармак челтәрен үстерү | | | | |
| 7. | Россия Федерациясе Спорт министрлыгы тарафыннан раслана торган тәртип нигезендә федераль спорт әзерлеге стандартларын тормышка ашыру эшчәнлеген гамәлгә ашыру хокукын алуга ирекле аккредитацияләүне оештыру һәм үткәрү | 2021 – 2025 еллар | Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, Татарстан Респуб-ликасының җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | Татарстан Республикасы Спорт министрлы-гының административ регламенты |
| 8. | Россия Федерациясе Спорт министрлыгы боерыгы нигезендә спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмалар эшчәнлегенә карата таләпләр билгеләү юлы белән аларның эшчәнлеген җайга салу | 2021 – 2025 еллар | Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, Татарстан Респуб-ликасының җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы боерыгы |
| IV. Спорт резервын әзерләү системасының кадрлар потенциалын үстерү | | | | |
| 9. | «Демография» илкүләм проектының «Спорт – тормыш нормасы» ярдәмче проектын тормышка ашыру кысаларында югары белем бирүче «Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм | ел саен | Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, югары белем бирүче «Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм академиясе» федераль дәүләт | квота кысаларында һөнәри яңадан әзерлек узуга гариза |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | академиясе» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе базасында «Спорт төрләре буенча спорт әзерлеге оешмалары тренеры» программасы буенча Татарстан Республикасы физик культура һәм спорт өлкәсендә белгечләрне һөнәри яңадан әзерләү курсларын узуга ихтыяҗны анализлау һәм һөнәри яңадан әзерләү курсларына заявкалар формалаштыру | | бюджет мәгариф учреждениесе (килешү буенча) | |
| 10. | Югары белем бирүче «Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм академиясе» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесендә физик культура һәм спорт тармагы кадрларын әзерләүгә максатчан шартнамәләр төзү | ел саен | Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, югары белем бирүче «Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм академиясе» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе (килешү буенча), Татарстан Республикасының җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | имзаланган максатчан шартнамә |
| 11. | Спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы тренерларга һәм башка белгечләргә өстәмә һөнәри белем бирү системасын камилләштерү буенча Россия Федерациясе Спорт министрлыгы тарафыннан кабул ителгән методик тәкъдимнамәләрне гамәлгә кертү | 2020 – 2021 еллар | Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, югары белем бирүче «Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм академиясе» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе (килешү буенча), Татарстан Республикасының җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы тренерларга һәм башка белгечләргә өстәмә һөнәри белем бирү буенча төзәтелгән программалар |
| 12. | «Татарстан Республикасының спорт | ел саен | Татарстан Республикасы Спорт | Татарстан |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | мәктәпләре һәм олимпия резервындагы спорт мәктәпләре арасында рейтинг», «Татарстан Республикасының иң яхшы спорт мәктәбе тренеры» смотр-конкурсларын (дүрт номинациядә: «Массалык», «Осталык», «Камиллек», «Яшь тренер») үткәрү | | министрлыгы, Татарстан Республикасының җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | Республикасы Спорт министрлыгы боерыгы |
| 13. | Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренә – яшь белгечләренә дәүләт ярдәме күрсәтү | ел саен | Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасының җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре арасында килешүләр |
| V. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның инфраструктурасын, финанслар белән һәм матди-техник яктан тәэмин ителешен үстерү | | | | |
| 14. | Кече спорт мәйданчыклары төзү өчен спорт-технологик җиһазлар сатып алу. Башка физкультура-сәламәтләндерү комплекслары һәм массакүләм спорт үзәкләрен төзү һәм реконструкцияләү | 2020 – 2022 еллар | Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, Татарстан Республикасының җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | Россия Федерациясе Спорт министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең «Электрон бюджет» дәүләт интеграция-ләнгән |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | | | системасында төзелгән килешү |
| 15. | Россия Федерациясе җыелма командалары өчен спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы спорт оешмаларына дәүләт ярдәме күрсәтү | 2020 – 2022 еллар | Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы | Россия Федерациясе Спорт министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең «Электрон бюджет» дәүләт интеграция-ләнгән системасында төзелгән килешү |
| 16. | Халыкара һәм бөтенроссия спорт ярышларында югары казанышлары өчен спортчыларга һәм тренерларга дәүләт ярдәме күрсәтү | ел саен | Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, Татарстан Респуб-ликасының җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы боерыгы |
| 17. | Спорт инвентаре һәм җиһазлары, кирәк-яраклар сатып алуга һәм спорт төрләрен үстерү чараларын үткәрүгә бәйле чыгымнарны каплау өчен дәүләт һәм муниципаль учреждениеләргә субсидияләр бирү | ел саен | Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгы проекты, имзаланган килешүләр |
| 18. | Татарстан Республикасында спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларны финанслау күләмнәрен мониторинглау һәм спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт һәм муниципаль оешмалар | ел саен | Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы | Россия Федерациясе Спорт министрлыгына доклад |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | тренерларының уртача эш хакы Татарстан Республикасындагы уртача эш хакына кадәр арту дәрәҗәсен мониторинглау | | | |
| VI. Спортка сәләтле балаларны сайлап алу системасын камилләштерү | | | | |
| 19. | Россия Федерациясе Спорт министрлыгы боерыгы белән расланган спортка сәләтле балаларны сайлап алу механизмнарын һәм критерийларын гамәлгә кертү | 2020 – 2021 еллар | Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, югары белем бирүче «Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм академиясе» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе (килешү буенча), Татарстан Республикасының җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы боерыгы |
| 20. | Спортка сәләтле балаларны, шул исәптән инвалид балаларга һәм сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затларга карата индивидуаль сайлап алу эше өчен җавап бирүче оешмалар (оешмаларның структур бүлекчәләре) эшчәнлеген гамәлгә ашыру буенча Россия Федерациясе Спорт министрлыгы тарафыннан кабул ителгән методик тәкъдимнамәләрне гамәлгә кертү | 2020 – 2021 еллар | Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, югары белем бирүче «Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм академиясе» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе (килешү буенча), Татарстан Республикасының җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | Россия Федерациясе Спорт министрлыгына доклад |
| VII. Фәнни-методик, медик-биологик яктан һәм допингка каршы тәэмин итү системасын камилләштерү | | | | |
| 21. | Спорт резервын әзерләү мәсьәләләре буенча фәнни һәм фәнни-гамәли конференцияләрдә катнашу һәм оештыру | 2020 – 2025 еллар | Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау | мәгълүмати-аналитик материаллар |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | | министрлыгы, югары белем бирүче «Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм академиясе» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе (килешү буенча), төбәк спорт федерацияләре (килешү буенча), Татарстан Республикасының җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | |
| 22. | Россия Федерациясе Спорт министрлыгы боерыгы белән раслана торган спорт резервын әзерләүне фәнни-методик яктан тәэмин итү тәртибен гамәлгә кертү | 2020 – 2021 еллар | Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы югары белем бирүче «Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм академиясе» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе (килешү буенча), төбәк спорт федерацияләре (килешү буенча), Татарстан Республикасының җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы боерыгы |
| 23. | Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмалар өчен допингка каршы материаллар бастырып чыгару | 2020 – 2021 еллар | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, югары белем бирүче «Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм академиясе» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе | Россия Федерациясе Спорт министрлыгына доклад |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | | (килешү буенча) | |
| 24. | Югары белем бирүче «Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм академиясе» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең профильле кафедралары һәм Спорт резервын әзерләү техноло-гияләре буенча укыту-фәнни үзәге булуын исәпкә алып, Татарстан Республикасы җыелма командалары каршындагы спорт резервындагы спортчыларны озатып йөрүче комплекслы фәнни төркемнәр булдыру | 2020 – 2025 еллар | югары белем бирүче «Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм академиясе» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе (килешү буенча), Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы | мәгълүмати-аналитик материаллар |
| VIII. Спорт ярышлары системасын камилләштерү | | | | |
| 25. | Россия яшүсмерләр һәм юниорлар беренчелекләрен, спартакиадалар һәм башка бөтенроссия балалар һәм яшүсмерләр рәсми спорт чараларын оештыру һәм үткәрү буенча методик тәкъдимнамәләрне гамәлгә кертү | 2019 – 2020 еллар | Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, төбәк спорт федера-цияләре (килешү буенча), Татарстан Республикасының җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | мәгълүмати-аналитик материаллар |

______________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 6 март, 168 нче
карары белән расланды

# 2025 елга кадәр Татарстан Республикасында спорт резервын әзерләү концепциясе

## Кереш

Бу 2025 елга кадәр Татарстан Республикасында спорт резервын әзерләү концепциясендә (алга таба – Концепция) 2025 елга кадәрге чорга Татарстан Республикасында спорт резервын әзерләү өлкәсендә өстенлекле максатлар һәм бурычлар билгеләнә.

Концепция Россия Федерациясе Президентының Россия Федерациясе Федераль Собраниесенә 2019 елның 20 февралендәге Юлламасы, Россия Федерациясе Президентының «2024 елга кадәрге чорга Россия Федерациясен үстерүнең илкүләм максатлары һәм стратегик бурычлары турында» 2018 елның 7 маендагы 204 номерлы Указы, «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» 2007 елның 4 декабрендәге 329-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 7 августындагы б-1101 номерлы боерыгы белән расланган 2020 елга кадәрге чорга Россия Федерациясендә физик культура һәм спортны үстерү стратегиясе, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Физик культура һәм спортны үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 15 апрелендәге 302 номерлы карары белән расланган «Физик культура һәм спортны үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 17 октябрендәге б-2245 номерлы боерыгы белән расланган 2025 елга кадәр Россия Федерациясендә спорт резервын әзерләү концепциясе, Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына 2018 елның 24 сентябрендәге Юлламасы, «2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен раслау турында» 2015 елның 17 июнендәге 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә эшләнде.

## 1. Спорт резервын әзерләү системасының торышы

Спорт резервын әзерләү – физик культура һәм спорт өлкәсендә эшчәнлек алып баручы төрле оештыру-хокукый рәвешләрдәге оешмаларда спорт төрләре буенча күпьеллык максатчан күнегүләр ясау процессы.

Татарстан Республикасында физик культура һәм спортны, спорт резервын әзерләү системасын үстерү үткәрелә торган социаль сәясәтнең өстенлекле юнәлеше булып тора.

Соңгы биш ел эчендә балалар һәм яшүсмерләр спортын үстерүнең һәм спорт резервын әзерләүнең төп күрсәткечләре уңай динамикага ия. Мәгълүматлар 1 нче таблицада күрсәтелгән.

1 нче таблица

| Спорт әзерлеге күрсәткечләре | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел |
|---|---|---|---|---|---|
| Татарстан Республикасында балалар һәм яшүсмерләр спорты, спорт резервын әзерләү | | | | | |
| Спорт мәктәпләренең гомуми саны, шулардан: | 169 | 171 | 172 | 170 | 170 |
| спорт мәктәпләре / спорт олимпия резервы мәктәпләре | 139/30 | 140/31 | 143/29 | 141/29 | 140/30 |
| Шөгыльләнүчеләр саны, | 87 776 | 86 615 | 90 558 | 91 335 | 90 675 |
| шулардан спорт әзерлеге этапларында: | | | | | |
| спорт-сәламәтләндерү этабы | 13 691 | 13 619 | 17 172 | 15 521 | 12 879 |
| башлангыч әзерлек этабы | 45 260 | 45 850 | 47 178 | 50 104 | 50 691 |
| күнегүләр ясау этабы | 28 054 | 26 245 | 25 389 | 24 841 | 25 244 |
| спорт осталыгын камилләштерү этабы | 670 | 792 | 700 | 716 | 747 |
| югары спорт осталыгы этабы | 101 | 109 | 119 | 153 | 144 |
| Спорт мәктәпләрендә спортның культивацияләнә торган төрләре саны | 68 | 73 | 75 | 77 | 73 |
| Спортчылар-разрядчылар әзерләнде (шулардан хисап елында әзерләнде) | 30 003 (17 195) | 33 109 (17 732) | 34 838 (17 475) | 33 708 (18 450) | 31 528 (20 601) |
| Барлыгы Россиянең спорт мастерлары (шулардан хисап елында әзерләнде) | 285 (101) | 281 (107) | 308 (104) | 341 (120) | 345 (99) |
| Барлыгы халыкара класслы спорт мастерлары (шулардан хисап елында әзерләнде) | 37 (11) | 33 (10) | 41 (10) | 47 (17) | 43 (15) |
| Барлыгы атказанган спорт мастерлары (шулардан хисап елында әзерләнде) | 5 (1) | 7 (2) | 5 (3) | 12 (4) | 11 (1) |
| Тренер-укытучылар составы | 2 892 | 2 828 | 2 844 | 2 893 | 3 009 |
| Штатта түбәндәге физкультура хезмәткәрләре бар | 2 165 | 2 168 | 2 246 | 2 278 | 2 342 |
| (процентта штат хезмәткәрләре): | (74,9%) | (76,7%) | (79%) | (78,4%) | (78%) |
| югары белемле | 1 848 | 1 896 | 1 969 | 2 017 | 2 087 |
| урта махсус белемле | 314 | 264 | 270 | 258 | 252 |
| Квалификация күтәрүне һәм яңадан әзерләүне үткән физик культура һәм спорт белгечләре | 591 | 439 | 534 | 570 | 575 |

Татарстан Республикасында спортка сәләтле балаларны ачыклауга һәм Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең җыелма командалары составына кирәргә сәләтле спортчыларны әзерләүгә юнәлдерелгән физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүләрнең күплелеген арттыру буенча эш алып барыла.

Спорт мәктәпләре саны 2015 елда 169дан 2019 елда 170кә кадәр артты. Яңа спорт мәктәпләрен ачу һәм спортның культивацияләнә торган һәм яңа төрләрен популярлаштыру спорт мәктәпләрендә шөгыльләнүчеләр санын арттыруга китерде, соңгы биш ел эчендә аларның саны 2 899 кешегә артты.

Шөгыльләнүчеләр саны арту белән беррәттән, югары класслы спортчыларны әзерләүнең сыйфаты буенча да уңай динамика бар. Бу юнәлешне түбәндәге

күрсәткечләр характерлый:

спорт осталыгын һәм югары спорт осталыгын камилләштерү этапларында спортчының спорт әзерлеген үтүе;

исемнәре булган спортчыларны әзерләү;

Татарстан Республикасы спортчыларының Россия Федерациясе җыелма командасы составына керүе.

Спорт осталыгын камилләштерү этапларында спорт әзерлеген – 747 кеше (2015 елда 670 кеше), югары спорт осталыгы этапларында 144 кеше (2015 елда 101 кеше) уза.

2015 елдан Россиянең гамәлдәге спорт мастерлары саны – 258 кешедән 345 кешегә кадәр, халыкара класслы спорт мастерлары – 37 кешедән 43кешегә кадәр һәм атказанган спорт мастерлары 5 кешедән 11 кешегә кадәр артты.

Спортның олимпия төрләре буенча Россия командалары составына Татарстан Республикасыннан 395 спортчы, Россия яшүсмерләр җыелма командалары (18 яшькә кадәр) составларына спортның олимпия һәм олимпия булмаган төрләре буенча 500гә якын спортчы керә. 2019 елда 254 инвалид спортчы Татарстан Республикасының җыелма командасы составына керде, 54 спортчы спортның паралимпия, сурдлимпия төрләре буенча Россиянең җыелма командасы составына кертелде.

Спорт резервын әзерләү системасында шөгыльләнүче спортчыларның гомуми саны 90 675 кеше тәшкил итә, шулардан түбәндәге спорт әзерлеге этапларында: 12 879 спортчы – спорт-сәламәтләндерү этабында, 50 691 спортчы – башлангыч әзерлек этабында, 25 244 спортчы – күнегүләр ясау этабында (спорт белгечлеге этабында), 747 спортчы – спорт осталыгын камилләштерү этабында һәм 144 спортчы югары спорт осталыгы этабында шөгыльләнә.

Татарстан Республикасында Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының спорт җыелма командалары өчен спорт резервын әзерләү системасында Татарстан Республикасының спорт төрләре буенча 105 аккредитацияләнгән федерациясе, югары белем бирүче «Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм академиясе» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының «Спорт әзерлеге үзәге» дәүләт автоном учреждениесе, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының «Республика физик культура һәм яшүсмерләр спорты үзәге» дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе, «Казан олимпия резервы училищесы» дәүләт бюджет һөнәри белем бирү учреждениесе эшли. Шулай ук 170 спорт мәктәбе (шулардан 140 спорт, 30 спорт олимпия резервы мәктәбе) 77 спорт төре буенча спортчылар әзерләүне гамәлгә ашыра, шул исәптән 48 олимпия, 8 паралимпия (терәк-хәрәкәт аппараты зарарланган затларның 5 спорт төре, сукырларның 3 спорт төре), 5 сурдлимпия спорт төре, интеллектуаль тайпылышлары булган затлар өчен 3 спорт төре. Шулардан 164е физик культура һәм спорт өлкәсендә идарә органнары ведомствосы карамагында тора, 6 спорт мәктәбе спорт клубларына (Казан шәһәре, Түбән Кама шәһәре, Әлмәт шәһәре) карый.

Татарстан Республикасының физкультура-спорт юнәлешендәге учреждениеләрендә шөгыльләнүчеләр белән күнегүләр ясау эшен 3 009 тренер шөгыльләнә, шулардан 2 342 кеше (78 процент) – штат хезмәткәрләре, 667 кеше (22 процент) – берьюлы ике эштә эшләүчеләр.

Штаттагы тренерлар арасыннан 2 087 кешенең югары һөнәри белеме, 252 кешенең урта һөнәри белеме бар. 27 кеше «Россиянең атказанган тренеры» исеменә ия. Штаттагы тренерларның гомуми саныннан 969 кешенең (41 процент) квалификация категориясе бар, шулардан:

307 тренернең (32 процент) – югары квалификация категориясе;

662 тренернең (68 процент) – беренче квалификация категориясе.

2015 елдан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыклары белән югары белем бирүче «Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм академиясе» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе базасында физик культура һәм спорт өлкәсендә учреждениеләрнең административ-идарә һәм тренерлар составларының квалификациясен күтәрү һәм аларны яңадан һөнәри әзерләү финанслана. 4 ел эчендә «Физик культура һәм спорт өлкәсендә идарә итүнең норматив-хокукый нигезләре», «Спорт менеджменты», «Спортның сайланган төрендә спорт күнегүләре ясауның заманча технологияләре» программалары буенча 1 500дән артык белгеч квалификациясен күтәрде һәм яңадан һөнәри әзерлек үтте.

«Демография» илкүләм проектының «Спорт – тормыш нормасы» федераль проектын тормышка ашыру кысаларында 2020 елдан югары белем бирүче «Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм академиясе» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе базасында «Спорт төрләре буенча спорт әзерлеге оешмалары тренеры» программасы буенча физик культура һәм спорт өлкәсендә белгечләрне яңадан һөнәри әзерләү курслары укыту квотасы нигезендә оештырылачак.

2015 күнегүләр ясау елыннан 2016 күнегүләр ясау елына кадәр Татарстан Республикасының спорт мәктәпләрен комплектлау, спорт мәктәпләрендә спорт әзерлеге программасына күчүне исәпкә алып, кимендә 10 процент һәм спорт олимпия резервы мәктәпләрендә оешмага укырга кергән затларның гомуми саныннан кимендә 30 процент гамәлгә ашырылды.

«Казан олимпия резервы училищесы» дәүләт бюджет һөнәри белем бирү учреждениесе 2017 елдан спорт әзерлеге программаларын тормышка ашыруга тулысынча күчте.

Федераль статистика күзәтүе мәгълүматлары буенча («Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмалар буенча мәгълүматлар» дигән 5-ФК номерлы форма), физик культура һәм спорт өлкәсендә оешмаларның (шул исәптән сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затлар һәм инвалидлар өчен оешмаларның) гомуми санында федераль спорт әзерлеге стандартлары нигезендә спорт әзерлеге буенча хезмәтләр күрсәтүче оешмаларның өлешен арттыру өлешендә Татарстан Республикасында дәүләт программасының индикатив күрсәткечен үтәү түбәндәгечә тәшкил итте:

2015 елда – 70 процент (Россия Федерациясе буенча – 70 процент);

2016 елда – 81 процент (Россия Федерациясе буенча – 75 процент);

2017 елда – 83 процент (Россия Федерациясе буенча – 80 процент);

2018 елда – 98 процент (Россия Федерациясе буенча – 90 процент);

2019 елда – 100 процент (Россия Федерациясе буенча – 95 процент).

Спорт резервын әзерләү системасын модернизацияләү кысаларында спорт резервын әзерләүнең төбәк системасы формалаштырыла. Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнеханов тарафыннан өстәмә белем бирү учреждениеләреннән

балалар һәм яшүсмерләр спорт мәктәпләре челтәрен спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларга үзгәртеп оештыру турында карар кабул ителде.

Татарстан Республикасында спорт резервын әзерләү оешмасында балалар һәм яшүсмерләр спорт мәктәпләре челтәрен үзгәртеп оештыру этаплап, балалар һәм яшүсмерләр спорт мәктәпләренең спорт төрләре буенча федераль спорт әзерлеге стандартларын тормышка ашыруга көчү әзерлегенә карап гамәлгә ашырыла. Татарстан Республикасында спорт резервын әзерләү системасын модернизацияләү кысаларында:

тренерлар кадрларын социаль яклауга бәйле мәсьәләләрне җайга салу буенча, шул исәптән эш хакы дәрәҗәсе, күнегүләр йөкләнеше нормасы һәм ел саен түләнә торган елларның озынлыгы турында кирәкле төбәк норматив актлары кабул ителде;

2018 елның 1 декабреннән 2019 елның 1 октябренә кадәр 164 дәүләт һәм муниципаль балалар һәм яшүсмерләр спорт мәктәбен өстәмә белем бирү учреждениеләреннән спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларга күчерү гамәлгә ашырылды.

Шулай итеп, Татарстан Республикасында билгеле бер идарә структурасы, норматив хокукый базасы, бюджетлар чыгымнары классификациясенең «Физик культура һәм спорт» бүлеге буенча финанслар белән тәэмин ителеше, шулай ук спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның тармак челтәре булган спорт тармагының мөстәкыйль социаль өлкә тармагы буларак формалашуы тәгәлләнде.

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы һәм «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе белән берлектә, спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмалары тарафыннан федераль спорт әзерлеге стандартлары таләпләре һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 24 апрель, б-926 нчы боерыгы белән расланган 2019 – 2025 елларга спорт әзерлеге программалары нигезендә спорт әзерлеге буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтүне финанслауны тәэмин итү буенча чаралар планы («юл картасы») эшләнде.

Чаралар планы («юл картасы») ел саен физкультура спорт оешмаларының спорт әзерләген оештыруга бәйле чыгымнарны финанслау күләмнәрен федераль спорт әзерлеге стандартлары таләпләре һәм 2019 – 2025 елларга спорт әзерлеге программалары нигезендә арттыруны күздә тота.

Эзлекле рәвештә спорт объектлары төзү буенча программалар тормышка ашырыла, аларның саны 11 065 берәмлек тәшкил итте. Һәр муниципаль берәмлектә йөзү бассейннары, боз сарайлары, спорт үзәкләре, универсаль спорт мәйданчыклары төзелде, модульле чаңгы базалары һ.б. актив төзелә башлады.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасында түбәндәгеләр эшли:

яссы спорт корылмалары – 5 922;

стадионнар – 46;

универсаль спорт заллары – 216;

ясалма боз белән түбәсе ябулы боз сарайлары (боз мәйданчыклары) – 45 (48);

җиңел атлетика манежлары – 10;

футбол манежлары – 1;

ат манежлары – 1;

чаңгы базалары – 80;

түбәсе ябулы йөзү бассейннары – 235, шулардан:

125е – 25 метрлы,

16сы – 50 метрлы,

2се – суга сикерү өчен,

92се – түбәсе ябулы йөзү бассейннарында кечкенә «касәләр» (10 х 6 метр);

спортның ишү төрләре өчен базалар – 2;

спортның ату төрләре өчен корылмалар – 191;

башка спорт корылмалары – 4 314.

Ел саен Татарстан Республикасы спортчылары төрле спорт төрләре буенча халыкара ярышларның мактау пьедесталларына күтәрелә. Безнең спортчылар олимпия, паралимпия, сурдлимпия уеннары, чемпионатлар, беренчелекләр, дөньякүләм һәм Европа кубокларында, шулай ук халыкара турнирларда җиңүләр һәм призлар алдылар.

Пхенчхан шәһәрендәге (Корея Республикасы) 2018 елгы XXIII кышкы Олимпия уеннарында чыгыш ясаган россиялеләр арасында 5 Татарстан Республикасы вәкиле булды. Уеннар йомгаклары буенча безнең олимпия спортчылары 4 медаль – 2 көмеш һәм 2 бронза медале яулады. 2018 елгы Паралимпия кышкы уеннарында Россиянең җыелма командасы составында Татарстан Республикасыннан Россиянең атказанган спорт мастеры Зәйнуллина Марта терәк-хәрәкәт аппараты зарарланган затлар арасында ике спорт төрендә – биатлон һәм чаңгы узышларында уңышлы чыгыш ясады. Спортчы көмеш һәм ике бронза медале яулады.

Спорт чараларының һәм физкультура чараларының календарь планы нигезендә, Татарстан Республикасында ел саен 800дән артык спорт чарасы, шул исәптән Россия һәм халыкара дәрәҗәдәге спорт чаралары үткәрелә.

Спортның олимпия, паралимпия, сурдлимпия төрләрен, махсус олимпиада затлары спортын үстерү һәм Россиянең җыелма командаларына спорт резервын әзерләү максатында, Россия Федерациясе Спорт министрлыгының «2018 – 2022 елларга спортның база төрләре исемлеген раслау турында» 2018 елның 25 апрелендәге 399 номерлы боерыгы белән Татарстан Республикасы өчен спортның 31 база төре билгеләнде (спортның 2 төренә, 29дан 31гә кадәр арттыру): бадминтон, бокс, велосипед спорты, су полосы, волейбол, гольф, ишү спорты, дзюдо, җиңел атлетика, өстәл теннисы, йөзү, суга сикерү, регби, синхрон йөзү, спорт көрәше, спорт гимнастикасы, стендка ату, теннис, тхэквондо, авыр атлетика, фехтование, футбол, чирәмдә хоккей, нәфис гимнастика, чаңгыда ике төр ярыш, чаңгы узышлары, чаңгы белән трамплиннан сикерү, сноуборд, хоккей, терәк-хәрәкәт аппараты зарарланган затлар спорты, сукырлар спорты.

Спортның база төрләрен үстерү буенча бурычларны тормышка ашыру кысаларында:

Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе Спорт министрлыгы арасында Физик культура һәм спортны үстерү өлкәсендә хезмәттәшлек һәм үзара хезмәттәшлек итү турындагы 2018 елның 7 ноябрендәге 52 нче килешүгә кул

куелды;

2018 елның 22 сентябрендә Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы һәм Халыкара йөзү федерациясе (FINA) арасында Казан шәһәрендә FINA су спорт төрләрен үстерү үзәген оештыру турындагы килешүгә кул куелды. Килешүгә кул куелган вакытта дөньяда шундый өч үзәк эшли иде: АКШта, Таиландта һәм Сенегалда;

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы һәм республиканың муниципаль берәмлекләре арасында физик культура һәм спортны үстерү өлкәсендә хезмәттәшлек һәм үзара хезмәттәшлек итү турындагы килешүләргә кул куелды. Спортның база олимпия һәм паралимпия төрләрен үстерү өчен алар республиканың муниципаль берәмлекләренә бүлеп бирелде;

спортның Татарстан Республикасына беркетелгән база олимпия һәм паралимпия төрләре буенча Россия Федерациясенең җыелма командаларына резерв әзерләүне гамәлгә ашыручы база оешмалары (учреждениеләре) билгеләнде;

Россия Федерациясе Спорт министрлыгы һәм Татарстан Республикасы арасында спортның база олимпия һәм паралимпия төрләре буенча Россия Федерациясенең җыелма командаларына спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы спорт оешмаларына адреслы финанс ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетына субсидия бирү турында ел саен килешү төзү билгеләнде.

## 2. Проблеманың тасвирнамәсе

Хәзерге вакытта спорт резервын әзерләү системасын алга таба үстерү төбәк һәм муниципаль дәрәҗәләрдә спорт резервын әзерләү бурычларын хәл иткәндә ведомстволар һәм дәрәҗәләр арасындагы хезмәттәшлек нәтиҗәлелеген арттыруны таләп итә.

1 нче таблицада китерелгән мәгълүматлардан күренгәнчә, Татарстан Республикасының спорт мәктәпләрендә башлангыч әзерлек этабыннан күнегүләр ясау этабына спортчыларның 50 проценты (Россия Федерациясендә – 63,4 процент), ә күнегүләр ясау этабыннан спорт осталыгын камилләштерү этабына спортчыларның бары 3 проценты кына (Россия Федерациясендә – 5,8 процент) күчә.

Спортчыны сайлап алу һәм бер этаптан икенче этапка күчерү системасы проблемаларын хәл итү һәм аны камилләштерү, спортчыларның яшенә адекват булмаган күнегүләр һәм ярышлар йөкләнешләрен куллану очракларын бетерү өчен федераль дәрәҗәдә федераль спорт әзерлеге стандартлары эчтәлеген актуальләштерү, шулай ук күнегүләр ясау процессын гамәлгә ашыруга бердәм методик алымнар эшләү таләп ителә.

Спортта көндәшлек көчәюгә бәйле рәвештә, методик, фәнни-методик, медик-биологик яктан тәэмин ителешнең сыйфатын даими камилләштерү, спорт резервын әзерләү системасында эксперименталь һәм инновацияле эшчәнлекне үстерү зарур.

Тренерлар кадрларына өстәмә һөнәри белем бирү системасын үстерүне, физик культура һәм спорт тармагының һөнәри стандартлары таләпләренә туры китереп, аларның гамәли һөнәри компетенцияләрен камилләштерүгә юнәлдереп гамәлгә ашырырга кирәк.

Спорт резервын заманча әзерләүнең төп проблемалары булып түбәндәгеләр кала:

күнегүләр ясау барышын гамәлгә ашыруга карата бердәм методик алымнар булмау;

спорт резервын әзерләүне фәнни-методик һәм медик-биологик яктан тәэмин итүнең төбәк моделе булмау;

тренерларның һәм тармак белгечләренең гамәли һөнәри компетенцияләрен камилләштерүгә юнәлдереп, тренерлар кадрларына өстәмә һөнәри белем бирүнең нәтиҗәле системасын төзү.

Шулай итеп, спорт резервын әзерләү буенча барлыкка килгән система үстерүне һәм камилләштерүне таләп итә.

## 3. Концепциянең максатлары һәм бурычлары

Концепциянең өстенлекле максатлары:

спорт җыелма командалары өчен спорт резервын әзерләүнең нәтиҗәлелеген һәм Россия спортының халыкара спорт аренасында көндәшлек сәләтен арттыру;

спорт әзерлеген үтүче затларның спорт осталыгы дәрәҗәсен күтәрү, аларның спортта гомерен озынайту;

Татарстан Республикасында халыкның физик активлыкка һәм спорт әзерлеге чаралары белән үз-үзен камилләштерүгә мотивациясен формалаштыруга физик культура һәм спортның йогынты ясавы дәрәҗәсен арттыру.

Концепциянең максатларына ирешү түбәндәге бурычларны тормышка ашыру юлы белән гамәлгә ашыру күздә тотыла:

спорт резервын әзерләү эшчәнлеге белән идарә итү, аны координацияләү һәм методик яктан тәэмин итү системасын камилләштерү;

спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның тармак челтәрен алга таба үстерү;

спорт резервын әзерләүне норматив хокукый җайга салуны камилләштерү;

спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы оешмалар өчен административ-идарә һәм тренерлар составларын әзерләү, аларның квалификациясен күтәрү һәм аларны яңадан әзерләү системасын камилләштерү;

спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның инфраструктурасын, финанслар, кадрлар белән һәм матди-техник яктан тәэмин ителешен үстерү;

федераль спорт әзерлеге стандартлары таләпләре нигезендә спортка сәләтле балаларны сайлап алу системасын камилләштерү;

фәнни-методик, медик-биологик яктан һәм допингка каршы тәэмин итүне камилләштерү;

спорт ярышлары системасын камилләштерү.

Спорт резервын әзерләү буенча өстенлекле бурычларны, шул исәптән бюджет тәэмин ителешен исәпкә алып, аларның сан-сыйфат күрсәткечләрен үтәү проект эшчәнлеге кысаларында кызыксынучы ведомстволар, муниципаль берәмлекләр, тармак оешмалары һәм республика спорт федерацияләре катнашында гамәлгә ашырылачак.

## 4. Концепцияне тормышка ашыру механизмнары

### 4.1. Спорт резервын әзерләүне норматив хокукый яктан җайга салуны камилләштерү

Спорт резервын әзерләүне норматив хокукый яктан җайга салуны камилләштерү түбәндәгеләрне күздә тота:

физик культура һәм спорт өлкәсендә башкарма хакимият органына федераль спорт әзерлеге стандартларын тормышка ашыручы оешмаларны ирекле аккредитацияләү вәкаләтләрен бирү өлешендә «Физик культура һәм спорт турында» 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү;

спорт резервын әзерләү системасын хокукый җайга салуның Концепция максатларына һәм бурычларына туры килүен мониторинглауны гамәлгә ашыру һәм физик культура һәм спорт турындагы Татарстан Республикасы законнарына, шулай ук башка норматив-хокукый актларга билгеләнгән тәртиптә тиешле үзгәрешләр кертү;

җирле үзидарә органнары һәм спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы оешмалар эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары, күрсәткечләре (максатчан индикаторлары) һәм инструментлары (методикалары) системасын камилләштерү;

күнегүләр ясау һәм спорт чараларын имин үткәрү шартларын тәэмин итү буенча норматив хокукый актларны камилләштерү.

### 4.2. Спорт резервын әзерләү системасы белән идарә итүне, аның эшчәнлеген координацияләүне һәм аны методик яктан тәэмин итүне камилләштерү

Спорт резервын әзерләү системасы белән идарә итү физик культура һәм спорт өлкәсендә уртак эш алып бару вәкаләтләре кысаларында федераль, төбәк һәм муниципаль дәрәҗәләрдә гамәлгә ашырыла.

Физик культура һәм спорт өлкәсендә федераль башкарма хакимият органы физик культура һәм спорт өлкәсендә бердәм дәүләт сәясәтен (спорт резервын әзерләүне кертеп) гамәлгә ашыра.

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы спорт резервын әзерләүнең төбәк системасын (спорт әзерлеге үзәкләрен үстерүне кертеп) формалаштыра, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының спорт җыелма командалары өчен спорт резервын әзерләүне тәэмин итә, Россия Федерациясенең спорт җыелма командалары өчен спорт резервын әзерләүне тәэмин итүдә катнаша, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар эшчәнлеген яраштыра.

Җирле үзидарә органнары Татарстан Республикасының спорт җыелма командалары өчен спорт резервын әзерләүгә шартлар тудыра һәм аны тәэмин итүдә катнаша.

Беркетелгән вәкаләтләр кысаларында Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, республика спорт федерацияләре һәм кызыксынучы ведомстволар

белән үзара хезмәттәшлек итеп, муниципаль берәмлекләр, ведомство буйсынуындагы оешмалар базасында, спорт төрләренең үзенчәлекләрен исәпкә алып, спорт резервын әзерләү системасын төзи.

Спорт резервын әзерләү белән идарә итү системасына спорт резервын әзерләүне оештыру-методик яктан тәэмин итү һәм аның эшчәнлеген яраштыру өчен җаваплы оешмалар керә.

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының «Спорт әзерлеге үзәге» дәүләт автоном учреждениесе, республика спорт федерацияләре белән үзара хезмәттәшлек итеп, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының спорт җыелма командаларына кандидатлар исемлегенә кертелгән спортчыларның Татарстан Республикасы спорт чараларының һәм физкультура чараларының календарь планындагы спорт чараларында катнашуын тәэмин итә, спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы оешмаларның эшчәнлеген координацияли һәм аларны методик яктан тәэмин итә, спорт төрләре буенча спортка сәләтле балаларны, шул исәптән инвалид балаларны һәм сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затларны ачыклау һәм сайлап алу процедурасында катнаша.

Спорт резервын әзерләү системасында идарә итүнең нәтиҗәлелеген арттыру максатларында Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының һәм җирле үзидарә органнарының спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларны ресурслар белән тәэмин итүдә бергәләп катнашу механизмнарын, шул исәптән оешмаларның спорт әзерлеге программаларын тормышка ашыруны тәэмин итү өчен спорт объектларыннан бергәләп файдалану механизмнарын формалаштырырга кирәк.

## 4.3. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның тармак челтәрен үстерү

Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмалар эшчәнлеген җайга салу аларның финанслар белән, матди-техник яктан, кадрлар һәм башка ресурслар белән тәэмин ителгән эшчәнлегенә, статусына һәм атамаларына, максатларына һәм бурычларына карата таләпләрне билгеләүдән гыйбарәт.

Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларга, аларның тибына һәм оештыру-хокукый рәвешенә карамастан, федераль спорт әзерлеге стандартларын тормышка ашыру эшчәнлеген гамәлгә ашыру хокукын алуга ирекле аккредитация узу мөмкинлеге биреләчәк.

Ирекле аккредитацияләү вакытында төп критерийлар булып тренерлар составына (шул исәптән белем һәм һөнәри әзерлек дәрәҗәсенә), матди-техник яктан һәм башка ресурслар белән тәэмин ителешенә, күнегүләр ясау һәм ярышлар процессларын гамәлгә ашыруга, спортчыларның спорт төрләре буенча федераль спорт әзерлеге стандартлары нигезендә күчү нормативларын үтәвенә карата таләпләр торачак.

Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларны ирекле аккредитацияләүне системалаштыру максатларында мондый оешмаларны ирекле аккредитацияләү тәртибен физик культура һәм спорт өлкәсендә федераль башкарма хакимият органы билгеләячәк.

Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмалар – эшчәнлегенең төп төре булып

спорт әзерлеге программаларын тормышка ашыру булган оешмалар.

Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмалар белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру лицензиясе булганда өстәмә гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашырырга хокуклы.

Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы төп оешмалар – спорт мәктәпләре, спорт-адаптив мәктәпләр һәм олимпия резервындагы спорт мәктәпләре.

Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмалар санына шулай ук олимпия резервы училищелары, шулай ук спорт юнәлешендәге интернат мәктәпләр керә, алар, шул исәптән, спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмалар базасында структур бүлекчәләр буларак оештырылырга мөмкин.

Студентлар спортын үстерү максатларында, югары белем бирүче мәгариф оешмалары федераль спорт әзерлеге стандартларын тормышка ашыру эшчәнлеген гамәлгә ашыруга хокук бирә торган ирекле аккредитацияләү нигезендә махсус төзелгән структур бүлекчәдә спорт осталыгын һәм югары спорт осталыгын камилләштерү этапларында спорт әзерлеге программаларын тормышка ашырырга мөмкин.

Шулай итеп, тармакара хезмәттәшлек гамәлгә ашырыла, бу вакытта теләсә нинди ведомство буйсынуындагы, типтагы һәм оештыру-хокукый рәвештәге спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешма спорт әзерлеге программаларын тормышка ашыру ярдәмендә спорт резервын әзерләүдә катнашу мөмкинлегенә ия була.

### 4.4. Спорт резервын әзерләү системасының кадрлар потенциалын үстерү

Спорт резервын әзерләү системасының кадрлар потенциалын үстерү түбәндәгеләрне күздә тота:

спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы оешмалар өчен административ-идарә составын һәм тренерлар кадрларын әзерләү, аларның квалификациясен күтәрү һәм аларны яңадан әзерләү системасын камилләштерү;

Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы физкультура спорт оешмалары эшчеләренә – яшь белгечләренә дәүләт ярдәме күрсәтү;

спорт мәктәпләре эшенең нәтиҗәлелеген арттыру, күнегүләр ясау барышының сыйфатын яхшырту, спорт мәктәпләренең административ һәм тренерлар составлары эшен төбәкара, федераль һәм башка спорт чараларында катнашу, шулай ук республика смотр-конкурслар үткәрү юлы белән стимуллаштыру.

### 4.5. Спорт резервын әзерләү инфраструктурасын үстерү, аны финанслар һәм матди-техник яктан тәэмин итү

Спорт резервын әзерләү инфраструктурасын үстерү, аны финанслар һәм матди-техник яктан тәэмин итү түбәндәгеләрне күздә тота:

«Татарстан Республикасында физик культура һәм спортны үстерү» дәүләт программасында һәм «Халыкның барлык категорияләре һәм төркемнәре өчен физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә шартлар тудыру, шул исәптән спорт

объектлары белән тәэмин ителеш дәрәҗәсен күтәрү, шулай ук спорт резервын формалаштыру» төбәк проектында каралган чаралар кысаларында спорт инфраструктурасын үстерү, спорт объектларын төзү һәм реконструкцияләү, спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның матди-техник базасын ныгыту, спорт җиһазлары, инвентаре һәм кирәк-яраклар белән тәэмин итү;

спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт һәм муниципаль оешмалар тренерларының уртача эш хакын Татарстан Республикасындагы уртача эш хакына кадәр күтәрү дәрәҗәсен мониторинглау.

## 4.6. Федераль спорт әзерлеге стандартлары нигезендә спортка сәләтле балаларны сайлап алу системасын камилләштерү

Федераль спорт әзерлеге стандартлары нигезендә спортка сәләтле балаларны сайлап алу системасын камилләштерү түбәндәгеләрне күздә тота:

спортка сәләтле балаларны сайлап алу һәм спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларга күчерү механизмнарын гамәлгә кертү;

спорт әзерлеген узу өчен «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ХОӘ) бөтенроссия физкультура-спорт комплексы сынаулары нормативларын (тестларын) үтәү барышында спортка сәләтле балаларны сайлап алу механизмнарын гамәлгә кертү.

## 4.7. Фәнни-методик, медик-биологик яктан һәм допингка каршы тәэмин итүне камилләштерү

Фәнни-методик, медик-биологик яктан һәм допингка каршы тәэмин итүне камилләштерү түбәндәгеләрне күздә тота:

спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмалар өчен допингка каршы материаллар бастырып чыгару;

югары белем бирүче «Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм академиясе» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең профильле кафедралары һәм Спорт резервын әзерләү технологияләренең укыту-фәнни үзәге булуын исәпкә алып, Татарстан Республикасының җыелма командалары каршында спорт резервындагы спортчыларны озатып йөрүче комплекслы фәнни төркемнәр булдыру;

спорт әзерлеге программалары буенча шөгыльләнүче затларда, тренерларда һәм физик культура өлкәсе белгечләрендә, спортта тыелган чаралар һәм (яки) ысуллар (допинг) кулланып, спорт нәтиҗәсенә ирешүгә нуль дәрәҗәдәге чыдамлыкны булдыру максатларында, Бөтендөнья допингка каршы кодексы нигезләмәләренә таянып эшләнгән мәгълүмати программаларны спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларга кертү.

## 4.8. Спорт ярышлары системасын камилләштерү

Спорт ярышлары системасын камилләштерү түбәндәгеләрне күздә тота:

муниципаль дәрәҗәдән республика дәрәҗәсенә кадәр спорт ярышларының кирәкле санын билгеләү;

зона ярышларын һәм комплекслы спорт ярышларын үткәрү системасын үстерү.

## 5. Концепцияне тормышка ашырудан көтелә торган нәтиҗәләр

Концепцияне тормышка ашыру буенча чаралар планы аның аерылгысыз бер өлеше булып тора, аның кысаларында спорт резервын әзерләү системасын камилләштерү буенча кирәкле чараларны гамәлгә ашыру күздә тотыла. 2025 елга кадәр чаралар планын тормышка ашыру барышында түбәндәге нәтиҗәләргә ирешү планлаштырыла:

спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда шөгыльләнүче һәм аларга спорт осталыгын камилләштерү этабында кабул ителгән затларның гомуми санында спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда шөгыльләнүче һәм аларга спорт осталыгын камилләштерү этабында кабул ителгән затларның өлешен 25 процентка кадәр арттыру;

физик культура һәм спорт өлкәсендә ведомство карамагындагы оешмаларда шөгыльләнүче затларның гомуми санында физик культура һәм спорт өлкәсендә ведомство карамагындагы оешмаларда спорт әзерлеге программалары буенча шөгыльләнүче затлар өлешен 100 процентка кадәр арттыру;

спорт әзерлеге программалары буенча шөгыльләнүче затларның гомуми санында спорт әзерлеге программалары буенча шөгыльләнүче, спорт разрядлары һәм исемнәре булган затлар өлешен 50 процент кадәр арттыру;

физкультура һәм спорт белән даими шөгыльләнүче 6 яшьтән алып 18 яшькә кадәрге сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затларның һәм инвалидларның гомуми санында халыкның әлеге категориясе өлешен 70 процентка кадәр арттыру.

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, төбәк спорт федерацияләре һәм кызыксынучы оешмалар белән берлектә, Концепцияне тормышка ашыру һәм аның нәтиҗәлелеген бәяләү, көтелә торган нәтиҗәләргә ирешү дәрәҗәсе мониторингы үткәреләчәк.

Татарстан Республикасында Концепцияне тормышка ашыру нәтиҗәсендә, аларның төп һәм мәҗбүри эшчәнлек төре ул спорт әзерлеге булган тармак оешмалары челтәре федераль, төбәк һәм муниципаль дәрәҗәләрдә кирәкле норматив хокукый, матди-техник яктан, кадрлар һәм башка ресурслар белән тәэмин ителеше белән алга таба үсеш алачак.

Спорт резервын әзерләү яңа сыйфатлы дәрәҗәдә булачак, бу спорт җыелма командалары өчен спорт осталыгы югары дәрәҗәдә һәм спортта озак яшәү потенциалы булган спорт резервын арттырырга мөмкинлек бирәчәк.